**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлеге составына керүче Бик-Үти авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**

25 ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Бик-Үти авыл җирлегенең Бик Үти авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Бик-Үти торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту өчен түләүгә Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2024 елның 25 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучылар исемлегенә 117 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 60 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 60 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлеге составына керүче Бик Үти авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2.««Бик-Үти авыл җирлегенең Бик Үти авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Бик-Үти торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту өчен түләүгә Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Бик-Үти авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Бик-Үти авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ Р.З.Җәләлетдинов

Бик-Үти авыл җирлеге
башлыгы _________________ Р.З.Җәләлетдинов